ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.01.2025 с.Старое Дрожжаное № 2

«Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләр «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен, тәрбия эшен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы Совет турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләр «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен, тәрбия эшен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы Совет турында» 2023 елның 28 декабрендәге 59 номерлы карарына (18.04.2024 № 8 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **4 пунктны** үз көчен югалткан дип танырга;

2) «Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләр «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен, тәрбия эшен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы Совет составы» **1 нче кушымтада**:

В.А. Баһаветдинованы составтан чыгарырга;

составка кертергә һәм вазыйфаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Алиуллова Ранилә Рамил кызы - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы буенча балалар һәм яшьләр Россия хәрәкәтенең җирле бүлекчәсе җитәкчесе, Совет сәркатибе (килешү буенча);».

2. Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләр «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен, тәрбия эшен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара

хезмәттәшлек итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы Совет сәркатибе, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы буенча балалар һәм яшьләр Россия хәрәкәтенең җирле бүлекчәсе җитәкчесе Алиуллова Ранилә Рамил кызын штаттан тыш нигездә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе статусы белән йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы М.Р. Гафаров